ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пункты һәм 2 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2018 елның 20 июне

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин В.П. Привалов шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин В.П. Привалов «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пункты һәм 2 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә аның гамәле Татарстан Республикасы

территориясендә яшәүче һәм әлеге Законның 2 статьясында күрсәтелгән категорияләренә керә торган Россия Федерациясе гражданнарына кагыла.

Дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы гражданнарның адреслы социаль ярдәм чаралары Татарстан Республикасы законнарында каралган тәртиптә күрсәтелә торган категорияләрен билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин В.П. Привалов — сугыш хәрәкәтләре ветераннары өчен каралган социаль ярдәм күрсәтү чараларын алучы. Гражданнарның әлеге категориясенә күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары күләмен җитәрлек түгел дип санап, шикаять итүче Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм гомуми юрисдикция судына мөрәҗәгать иткән. Ләкин мөрәҗәгатьләре, ул билгеләгәнчә, уңай нәтиҗәгә китермәгән.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3 пункты буенча Россия Федерациясе субъектлары әлеге Федераль законның 14—19 һәм 21 статьяларында билгеләнгән социаль ярдәм күрсәтү чараларына өстәмә рәвештә башка социаль ярдәм күрсәтү чараларын Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлар белән билгели ала.

Шул ук вакытта карала торган Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре белән социаль ярдәм күрсәтүнең андый өстәмә чаралары билгеләнмәгән, шуның белән, гражданин В.П. Привалов фикеренчә, аның конституциячел хокуклары бозыла. Шулай, мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясенең башка субъектлары үзләренең законнарында социаль ярдәм күрсәтүнең тиешле өстәмә чараларын социаль гаделлек таләпләренә тулысынча җавап бирә торган күләмдә билгеләгәннәр дип күрсәтә. Шул ук вакытта, ул билгеләгәнчә, Татарстан Республикасы Конституциясе белән билгеләнгән югары социаль стандартлар республика законнарында чагылыш тапмаган. Шуның белән, аның фикеренчә, республика закон чыгаручысы

тарафыннан каралган җайга салу федераль законнарга каршы килми, ләкин Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә, чөнки анда социаль хокукларның әһәмиятле өлеше бар һәм ул Россия Федерациясенең башка субъектлары белән чагыштырганда социаль гарантияләрнең югарырак дәрәҗәсен беркетә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин В.П. Привалов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктын һәм 2 статьясын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законда (2013 елның 21 декабрендәге 371-ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә) каралганча, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел. Әлеге статьяда каралган вәкаләтләрне финанслау Россия Федерациясе субъектының бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла, шулай ук федераль бюджеттан өстәмә акча бүлеп бирү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында гражданнарның Татарстан Республикасында адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган категорияләрен, шулай ук аларны күрсәтүнең конкрет күләмнәрен һәм рәвешләрен билгеләгән.

Татарстан Республикасы Конституция суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законы белән каралган билгеләнеше тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган гражданнарның аерым категорияләренең матди уңайлыкларына ярдәм итү булган хокукый җайга салу максатчан төсмергә ия һәм гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чарасы булып тора, аны билгеләү — Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы. Бу аны бирү нигезләре һәм шартлары социаль-икътисади үсешнең әлеге этабындагы финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата (2016 елның 8 июлендәге 12-О номерлы һәм 2017 елның 12 июлендәге 32-О номерлы билгеләмәләр).

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә туры килеп тора, ул билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклауны Россия Федерациясе һәм аның субъектларының уртак карамагына кертеп (72 статья, 1 өлешнең «ж» пункты), гражданнарның теге яки бу категорияләренә бирелә торган мондый яклауның конкрет ысулларын һәм күләмнәрен билгеләми. Әлеге мәсьәләләрне хәл итү закон чыгаручының аерым хокукы булып тора, ул Россия Федерациясе Конституциясендә беркетелгән хокукларны гамәлгә ашыру гарантияләрен билгеләгәндә социаль яклау чараларын, аларны дифференциацияләү критерийларын сайлап алуда, күрсәтелү шартларын һәм тәртибен регламентлаштыруда җитәрлек дәрәҗәдә иркле эш итә; ул шулай

ук аларның күрсәтелү формаларын (ысулларын) сайлап алырга һәм үзгәртергә хокуклы (2009 елның 10 ноябрендәге 17-П номерлы Карар; 2010 елның 9 ноябрендәге 1439-О-О номерлы Билгеләмә).

Шуның белән дәгъвалана торган нормалар үзләреннән-үзе гражданнарның, шул исәптән гражданин В.П. Приваловның да конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмый һәм, димәк, аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый. Гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү тәртибен үзгәртү турында ул куйган мәсьәләне хәл итү, шул исәптән аларны бирү күләмен киңәйтү гамәлдәге законнарга үзгәрешләр кертүне күздә тота, бу исә республика закон чыгаручысы компетенциясенә керә һәм Татарстан Республикасы Конституция судының «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән вәкаләтләренә карамый.

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пункты һәм 2 статьясы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин

В.П. Привалов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин В.П. Приваловка һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 8-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**